# Татарстан Республикасы ЗАКОНЫ

## Татарстан Республикасының архив законнарын бозган өчен административ җаваплылык турында

Әлеге Закон «Татарстан Республикасының архив фонды һәм архивлар турында» Татарстан Республикасы Законы нигезендә гражданнар, җәмгыять һәм дәүләт мәнфәгатьләрендә архив документларының сакланышын тәэмин итүгә юнәлтелгән.

Әлеге Законның гамәлдә булуы эшчәнлекләре барышында билгеләнгән тәртиптә Татарстан Республикасының архив фонды составына кертелүче даими һәм вакытлы сакланышлы документлар барлыкка килә торган барлык оешмаларга, учреждениеләргә һәм предприятиеләргә кагыла.

**1 статья.** Архив документларыннан файдаланганда аларны бозган яисә югалткан, шулай ук аларны законсыз юк иткән өчен –

урындагы затларга - хезмәт өчен түләүнең утыз минималь күләменә кадәр, гражданнарга хезмәт өчен түләүнең биш минималь күләменә кадәр штраф салына.

**2 статья.** Архив документларын тиешле дәүләт архивына тапшыру буенча законнарда билгеләнгән йөкләмәләрне урындагы затлар үтәмәгән өчен –

кисәтү ясала яисә хезмәт өчен түләүнең егерме минималь күләменә кадәр штраф салына.

Архив документларын бозуга яисә югалтуга китергән шул ук гамәлләр өчен –

хезмәт өчен түләүнең утыз минималь күләменә кадәр штраф салына.

**3 статья.** Архив документларын саклау шартларын һәм аларның сакланышын тәэмин итү буенча законнарда билгеләнгән йөкләмәләрне урындагы затлар үтәмәгән, шулай ук тиешенчә үтәмәгән өчен –

хезмәт өчен түләүнең ун минималь күләменә кадәр штраф салына.

Исп. тел 64-
[illegible]

328

**4 статья.** Даими һәм вакытлы саклanyштагы документларны тиешле архивларга тапшыру өчен сайлап алуның һәм әзерләүнең норматив хокукый актлар белән билгеләнгән тәртибен бозган өчен -

кисәтү ясала яисә урындагы затларга хезмәт өчен түләүнең ун минималь күләменә кадәр штраф салына.

**5 статья.** Татарстан Республикасы архив фондының архив документларын дәүләт исәбенә алуның һәм алардан файдалануның билгеләнгән тәртибен бозган өчен -

кисәтү ясала яисә урындагы затларга хезмәт өчен түләүнең егерме минималь күләменә кадәр, ә гражданнарга хезмәт өчен түләүнең ун минималь күләменә кадәр штраф салына.

**6 статья.** Оешмада гражданнарның хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен тәэмин итү өчен кирәкле социаль-хокукый мәгълүматлы документлар булганда, гражданнарга архив белешмәләре бирүдән нигезсез баш таркан өчен -

урындагы затларга кисәтү ясала яисә хезмәт өчен түләүнең егерме минималь күләменә кадәр штраф салына.

**7 статья.** Татарстан Республикасы архив фондының дәүләт өлешендәге, шулай ук билгеләнгән тәртиптә аеруча кыйммәтле яисә уникаль документлар категориясенә кертелгән документлардан яшерен архивлар төзегән өчен, йә гражданнарның хокукларына һәм законлы мәнфәгатьләренә кагылышлы яшерен архивлар төзегән өчен -

урындагы затларга һәм гражданнарга хезмәт өчен түләүнең егерме минималь күләменә кадәр штраф салына.

**8 статья.** Архив эшләре идарәсе органнарының архив законнарын бозуны бетерү турындагы күрсәтмәләрен урындагы затлар үтәмәгән өчен –

кисәтү ясала яисә урындагы затларга хезмәт өчен түләүнең егерме минималь күләменә кадәр штраф салына.

**9 статья.** Әлеге Законның 1-8 статьяларында күрсәтелгән административ хокук бозулар турындагы эшләр архив эшләре идарәсе органнарының урындагы вәкаләтле затлары төзегән административ хокук бозулар турындагы беркетмәләр нигезендә дәүләт хакимияте һәм идарәсенең җирле органнары каршындагы административ комиссияләр тарафыннан карала.

329

**10 статья.** Әлеге Законда күрсәтелгән административ хокук бозулар турындагы эшләрне алып бару һәм административ хокук бозулар турындагы карарларны үтәү административ җәзалар бирү законнарда билгеләнгән тәртиптә һәм вакытларда башкарыла.

**11 статья.** Әлеге Закон нигезендә салынучы штрафлар суммалары штраф салу турында карар кабул иткән орган урнашкан шәһәрләр һәм районнар бюджетларына җибәрелә.

**12 статья.** Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты

М.Шәймиев

Казан шәһәре,
2001 елның 27 июне
№ 897